| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.12.2020 ел Баулы шәһәре №237

Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү башкаруда социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән социаль норма чикләрендә гражданнарның түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүне һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын билгеләргә:

педагогик хезмәткәрләргә, мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәдәният өлкәсе хезмәткәрләренә - торак, җылылык, яктырту өчен түләүгә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы пенсиягә чыккан кешеләр өчен дә саклана (әгәр алар авыл җирлегендә урнашкан мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәгән булсалар һәм шунда яшәсәләр).

Социаль ярдәм чараларын алучы гражданнарның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш.

2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын

күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче учреждениеләргә социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров